**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 14 май № 343

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү турында» 2015 ел, 2 апрель, 214 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Сәламәтлек саклау учреждениеләре эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм халыкка медицина тәэминаты буенча эшне оештыруны камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү турында» 2015 ел, 2 апрель, 214 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарны түбәндәге эчтәлекле яңа 2 пункт белән тулыландырырга:

«2. Әлеге карарның көче 2015 елның 1 гыйнварыннан килеп туган хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.»;

2 пунктны 3 пункт дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\343.doc